Казан шәһәре Совет районының
«48нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе

# Балалар бакчасында кечкенәләр төркемендә режим моментлары

Казан, 2021

Кече яштәге балаларга режим моментлары үткәрү, аларга татар телен өйрәнүгә бик булыша. Икенче нечкеләр төркемендә режим вакыты- 15-20 мин.

Кече яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтү, сөйләм үстерү мәсьәләләрен чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундыйларның берсе- ***бармак уеннары***. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интелект усешендә уңай йогынты ясый. Мәсәлән:
“Йозак” уены
Тора йозак ишектә,
Ачып булмый ничек тә.
Каккалыйбыз, боргалыйбыз, тарткалыйбыз
Һәм ачабыз.
“ ***Песием, песием***” уены
( Баланың кул аркасын сыйпап.)
Песи, песи, пес итәр,
Ана песи, сөт эчәр,
Ана песи, сөт эчкәндә
Ата песи күз кысар
Ал дигәндә алмасаң
Лап итәр дә шап итәр!
“Лап итәр” дигәндә сыйпаган теге баланың кулын тартып алып өлгермәсә, тегесе сыйпаучы, монысы сугучы була.
“ ***Чәбәк-чәбәк***” уенын балалар бик теләп уйныйлар.
“Чәп-чәп чәбәкәй” – нәниләр кулларын күтәреп, чәбәклиләр.
кулларыбыз бәләкәй
Ә хәзер тизрәк-тизрә - кулларны җиңелче генә тезләргә суккалау
Чәбәклик күңеллерәк.

Нәни балалар үзләрен мактаганны, матур дип әйткәнне бик яраталар һәм аларның бик тиз үсәселәре килә.
“***Үсәбез***” уены.
Мин әле бик кечкенә
Миңа бары өч кенә.
Үсә, үсә зур булам
Бик матур малай (кыз) булам
- Балалар алга таба иеләләр,
- Күтәреләләр,
Ике кулның да имән бармакларын бит уртасына куеп башларын чайкыйлар.

Төрле предметлар тотып биегән уеннарны да киң кулланам. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар: “куян булып сикерәләр”, “ кошлар булып очалар”, “ җим

чүплиләр” һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын баета, үстерә.
“ ***Ак куянга ни булган***” аз хәрәкәтле уенын балалар бик яратын башкаралар.
*Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына кереп, бер бала чүгәли Ул — "куян ". Куян, бер кулын ияген куеп, моңаеп утыра. Түгәрәктәгеләр җырлый-җырлый әйләнәләр:*

Ак куянга ни булган,
Әллә инде авырган? Иптәшен
дә табалмый, Урыныннан да
торалмый, Куян, куян, син
сикер, Иптәшең табып китер!

*Куян биленә таянып сикерә башлый. Аннан бер иптәшен уртага алып әйләнәләр дә, чакырылган бала куян булып кала. Уен шулай дәвам итә.*

“***Туп***” уены
Туп, туп матур туп,
Сикер, сикер матур туп!
Бер-ике, бер-ике!
Сикер, сикер матур туп! (сикерәләр)

Шулай ук Р. К. Шаехованың “Раз – словечко, два - словечко” ярдәмлегеннән иркен файдаланам. Кечкенә хикәяләр белән таныштырам, балалар игътибар белән тыңлыйлар, аерым сүзләрне тиз истә калдыралар. “Тәрҗемә ит” дигән уен аша өйрәнгән сүзләрнең татарча тәрҗемәсен искә төшерәбез, яки “серле капчык”тан уенчыклар алалар һәм аларны татарча атыйлар. Алдагы уку елына күпер әнә шулай әкренләп салына.